

# МӘЖИТ ҒАФУРИ 1880-1934

# ТОРМЫШ ЮЛЫ

❖1880 елда Башкортстанның Гафури районы Җилем-Каран авылында укытучы-хәлфә гаиләсендә туа.

❖Үз авылларындагы мәдрәсәдә укый, аннары күрше Үтәш авылындагы мәдрәсәгә күчә.

❖Әтисе белән әнисе үлеп китә, һәм моннан соң унбер-унике яшьлек Мәҗиткә үз көнен үзе күрергә туры килә.

❖1896 елда берәр зуррак мәдрәсәдә укуын дәвам иттерү теләге белән ул Өфегә килә, әмма ярлылыгы аркасында теләгенә ирешә алмый, бары 1898 елда гына, Троицк шәһәренә барып, мәдрәсәгә укырга керә.

- ❖Троицк мәдрәсәсендә укыганда беренче әдәби тәҗрибәләрен ясый. 1904 нче елдан аның язганнары китап рәвешендә дөнья да күрә башлый.
- ❖"Фәкыйрьлек берлә үткән тереклек", "Себер тимер юлы, яки әхвале милләт" кебек беренче китаплары басылып чыга.
- ❖1905 елда, Казанга килеп, "Мөхәммәдия" мәдрәсәсенә укырга керә һәм шул вакытта илдә көчәйгән революцион хәрәкәт йогынтысында үз иҗатында туган халкының реаль тормышына игътибарын көчәйтә, милли азатлык идеяләрен чагылдыра башлый.

- 1906 елда М.Гафури кабат Өфегә китә.
- 1917 нче елга кадәрге иҗатын да ул үзен милләт язмышын кайгырткан, аның азатлыгы өчен көрәшкән әдип итеп таныта.
- М. Гафури 1934 елда Өфе шәһәрендә вафат була.

# ИҖАТЫ

- "Фәкыйрьлек берлә үткән тереклек»
- "Себер тимер юлы, яки әхвале милләт»
- "Кара йөзләр»
- "Тормыш баскычлары»
- "Шагыйрьнең алтын приискасында»
- “Кызыл йолдыз” пьесасы
- ”Эшче” операсының либреттосы

- Мәҗит Гафури бер генә телдә — татар телендә иҗат иткән. Совет чорында Мәҗит Гафуриның әсәрләре башкорт, рус һәм башка милли телләрдә бик күп мәртәбәләр басылган. 1954-1957 еллар арасында Башкортстан китап нәшриятында әдипнең башкортча тәрҗемәдә алты томлык әсәрләр җыелмасы һәм 1980-1984 елларда Татарстан китап нәшриятында дүрт томлыгы дөнья күрде.

